КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 394

Психоневрология интернатлары исемен алмаштыру турында

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 ел, 18 декабрь, 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәгеләр исемен алмаштыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«Алабуга психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе исемен «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Алабуга интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе итеп;

«Зеленодольск психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе исемен «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Зеленодольск интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе итеп;

«Казан психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе исемен «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Казан интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе итеп;

«Тернәкләндерүнең заманча медицина-социаль технологияләре кулланыла торган Кама Аланы психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе исемен – «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Кама Аланы интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе итеп;

«Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе исемен «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен

билгеләнгән Яңа Чүриле интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе итеп;

«Чистай психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе исемен «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Чистай интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе итеп;

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына календарь көннәрдә исәпләнә торган 90 көн эчендә бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре уставларына тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин